ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
09.11.2020 ел. № 4

Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын-Чишмә торак пунктында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Кәрәкәшле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Салкын-Чишмә авылы, Фрунзе урамы, 4А йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасы янында 2021 елда Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын Чишмә торак пунктында гражданнар җыенын 2020 елның 23 ноябрендә 10.00 сәгатьтә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Салкын-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъдык яшенә җиткән гражданнардан 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга ризамы:

-Салкын-Чишмә авылының Чапаев урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», http://jutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев